ГЛАВА БУРНАШЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
БОРНАШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ  КАРАР

17.10.2022  с. Татарское Бурнашево  2

Югары Ослан муниципаль районы Борнаш авыл җирлегенең Каинки авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү  турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 ст., Югары Ослан муниципаль районы Борнаш авыл җирлеге Уставының 24 ст. нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2022 елның 30 октябренә Югары Ослан муниципаль районының Борнаш авыл җирлегенең Каинки авылында  гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2.Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«2023 елда Югары Ослан муниципаль районының Борнаш авыл җирлегенең Каинка авылы территориясендә теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 1500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юллау белән килешәсезме:

- Каинка авылында юлларны ремонтлау өчен, товарны китерү өчен билгеләнгән пунктка кадәр илтеп җиткерүче хисабына вак таш сатып алу

«ӘЙЕ»  «ЮК»

3. Гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча уздырырга: Каинка авылы, Үзәк ур., 18 йорт 10.30 сәгатьтә.

4. Борнаш авыл җирлеге Башкарма комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Югары Ослан муниципаль районы
Борнаш авыл җирлеге башлыгы  С. В. Бурукин